“Зат алмашлыклары” темасы 6нчы сыйныфта “Алмашлык” бүлегендә 1 сәгать өйрәнелә.
Дәреснең тибы: Яңа материалны өйрәтү.
Дәреснең тибы аның эчтәлегенә туры килә: укучыларны кызыксындыру, актульләштерү, яңа теманы өйрәтү, алынган белемнәрне ныгыту, камилләштерү, дәреснең дидактик максатыннан караганда, бик отышлы.
Әлеге дәрестә укытуның традицион метод һәм алымнары белән беррәттән яңа педагогик технологияләр дә кулландым. .Белем һәм тәрбия бирүгә комплекслы якын килеп, дәресемдә балаларның тәрбиялелеген күтәрү өстендә дә эшләргә тырыштым.
Дәреснең төзелеше:
1.Оештыру өлеше.
2. Белемнәрне хәтердә яңарту.
3.Яңа теманы аңлату.
4.Белемнәрне билгеле бер системага салу, гомумиләштерү.
5.Йомгаклау.
Дәресемә түбәндәге максатларны куйдым:
Максатлар: информацион-коммуникатив технологияләр куллану шартларында "алмашлыклар" темасын аңлату; алган белемнәрне биремнәр эшләүдә куллана белергә күнектерү; иҗади фикерләү сәләтләрен, игътибарлылыкны үстерү өстендә эшне дәвам итү; мәрхәмәтлелек, бер-беребезгә карата яхшы хисләр тәрбияләү.

Минем фикеремчә, дәрескә куелган барлык максатларга ирешелде. Укучыларны дәрестә пассив тыңлаучы итеп түгел, ә танып белү процессында актив катнашучы итеп күрә белү дәрестә минем төп бурычым иде. Яңа теманы бирүдә информацион коммуникатив технологиялэр кулланып, укучыларнын ижади фикерлэу сәләтен үстерү өстендә зшләдем. Халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итеп, яңа теманы үзләштерүдә кызыксыну уяттым, ә республикабыз һәм илебез тормышындагы көнүзәк проблемаларга тукталып, укучыларда ватанпәрварлык хисләре тәрбияләдем, дип уйлыйм.Дәрестә һәр баланың фикерен сорап бетерү мөмкин түгел, шулай да, дәрестә һәрбер укучыга үзенең фикерен әйтү мөһим. Бу исә укучыларны үзләрен шәхес итеп тоярга мөмкинчелек бирә. Дәрес барышында укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен, осталыкларын мөстәкыйль рәвештә куллана белү эзлеклелеге тәэмин ителде. Теманы ныгыту максатыннан тест эшләнде. Укучыларның белемнәре бәяләнде һәм ФГОС таләпләренә ярашлы рәвештә өй эше бирелде

Тема: Зат алмашлыклары

Максатлар: информацион-коммуникатив технологияләр куллану шартларында "алмашлыклар" темасын аңлату; алган белемнәрне биремнәр эшләүдә куллана белергә күнектерү; иҗади фикерләү сәләтләрен, игътибарлылыкны үстерү өстендә эшне дәвам итү; мәрхәмәтлелек, бер-беребезгә карата яхшы хисләр тәрбияләү.

Җиһазлау: "Татар теле", Р.К.Сәгъдиева, 2016, проектор, слайдлар, рәсемнәр.

Метод һәм алымнар: әңгәмә, өлешчә эзләнү, тест.

Дәрес тибы: яңа теманы аңлату.

Дәрес барышы.

1. **Оештыру моменты.**

- Исәнмесез, укучылар! Бүген татар теле дәресен сездә мин – Балтач районы Иске Тимкә урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хөрмәтова Эльвера Мәгдән кызы алып барам. Дәресне башлыйбыз! Кадерле укучылар, әйдәгез бер-беребезгә чын күңелдән елмаешыйк та, хәерле көн телик.
  - **№ 1 слайд шигырь юллары**
- Хәерле көн миңа,
  Хәерле көн сиңа,
  Хәерле көн сезгә,
  Хәерле көн барыбызга!
- Менә тагы да күркәмләнде мөлаем йөзегез.

Укучылар, үткән дәрестә сез алмашлык сүз төркемен өйрәнә башладыгыз.Үткәннәрне искә төшерү максатыннан **Сорауларга телдән җавап бирәбез.**

1. Алмашлык сүзе нинди сүздән барлыкка килгән? *(алмаштыру*). Мәсәлән, алмаш аяк киеме, алмаш өс киеме
2. Ә нинди сүз төркемнәрен алмаштыра соң ул? (*Исемне, сыйфатны, сан һәм рәвешне алмаштырып килүче мөстәкыйль сүз төркеме).*
3. Алмашлыклар сөйләмдә нәрсә өчен кирәк? (*Сөйләмне кабатлаудан коткаралар, аны җыйнак һәм матур яңгырашлы итәләр*). Димәк, алмашлыклар башка сүз төркемнәре кебек бик әһәмиятле икән.

- Укучылар, безнең татар халкы элек-электән атна кичләрендә әкиятләр сөйләргә, тыңларга яраткан. Мин дә сезгә бер әкият алып килдем, ә сез игътибар белән тыңлап утырыгыз.

(Әкият укыганда явыз карчык һәм халык күренеше слайдта)

№ 2 слайд авыл күренеше төшкән рәсем

- Борын-борын заманда яшәгәннәр ди бик яхшы һәм киң күңелле кешеләр, алар үз көннәрен үзләре күреп, яхшы эшләп байлыкта яшәгәннәр, дус булганнар ди. Аларның ихлас дуслыкларын куреп, күрше авылда яшәгән бер явыз карчыкның ачуы кабарган. Ул карчык турында сезнең дә ишеткәнегез булгандыр әле, укучылар. Әйе, батырларны юлдан яздыручы, матурларны уттан алып, суга салучы убырлы бу якларга да килеп чыккан икән шул. Килеп тә чыккан, үзенең явыз гамәлләрен кыла да башлаган. Иң беренче эш итеп, боларны сихерләргә булган, барысы да үзләренең исемнәрен онытсыннар, бер-берләренә эндәшә алмасыннар дигән. Һәм шулай булган да, болар исемнәрен онытканнар, әти-әниләре балаларына, балалар дусларына, туганнарына ничек дип тә эндәшергә белмәгәннәр, бер-берләрен аңламый башлаганнар. Якты көннәре караңгыланган, көлүне оныткан бу кешеләр. Шулай исемнәрен онытып, кемнән ярдәм сорарга белмичә аптырашып торганда бу авылга әкиятләрдә генә очрый торган Аксакал карт килеп

төшкән. Аны күрү белән кайгыга баткан халыкта өмет чаткылары кабынган, бары тик ул гына ярдәм итсә итәр дип, үзләренең башларына төшкән хәсрәтне сөйләп биргәннәр, явыз карчыкны караклыкта гаепләгәннәр.

-Яхшы, мин сезгә ул урлаган исемнәрегезне табып кайтарттырырмын. Ләкин бу бик тиз булмас, булганны югалту тиз, кирегә эзләп табу, ай-һай озак. Әлегә сез , исемнәрегез урынына алмашка *МИН, СИН, УЛ, БЕЗ, СЕЗ, АЛАР* дигән тылсымлы сүзләрне кулланып торырсыз, дигән һәм юлга кузгалган.

№ 3 слайдка мин син, ул, без, сез, алар языла очып килү- рәвешендә.

Аксакал юлында булсын, ә без әлеге сүзләргә игътибар итик әле, бу нинди сүзләр?

- Дөрес, алмашлыклар.

Ә хәзер балалар дәресебезнең темасын тулысынча ачыклар өчен явыз карчыкның беренче сынавын үтәргә кирәк, ул ребус чишү. ,, ,,, ы=а ,,

60

Ал маш лык

Бик балалар , дөрес. Бүгенге дәресебезнең темасы Зат алмашлыклары. Хәзер дәфтәрләребезне ачып бугенге датаны һәм теманы язабыз. Буген уникенче март, пәнҗешәмбе, яки атна киче. Сыйныф эше. Зат алмашлыклары.

№ 4 слайд алмашлыклар дип язылган

- Сөйләм барышында катнашучы затларны белдерә торган алмашлыклар зат алмашлыклары дип аталалар. Алар 3 затта киләләр.

- Хәзер парларда эшләп алыйк әле.(таблицаны тутыру)
- Мин, син,ул,без,сез,алар.

	Берлек сан	Күплек сан
I зат		
II зат		
III зат		

- Таблицага карап, бергәләп нәтиҗә чыгарыйк. (1 нче, 2 нче, 3 нче зат алмашлыклары була; берлек һәм күплек санда киләләр)
- Сез алмашлыгын кайчан берлек санда кулланабыз? (Кешене олылап, хөрмәт итеп әйткәндә...)120 нче биттәге кагыйдә белән танышабыз. Мәсәлән, котлау, чакыру хатлары язганда без бу кагыйдәне истә тотарга тиешбез.
- Беренче, икенче зат алмашлыклары сөйләү процессында катнашкан затларны белдерәләр. Хәзер сез үзегез дә әйтә аласыз:
  - 1 нче зат – мин, без/ сөйләүче кешеләрне белдерә
  - 2 нче зат – син, сез/ алар тыңлаучы кешеләрне белдерә
  - 3 нче зат алмашлыклары- ул, алар/ үзләре сөйләм процессында катнашмыйлар, бары тик алар турында сүз бара.

- Димәк, нинди нәтиҗә ясыйбыз? (1 нче зат- сөйләүче, 2 нче зат- тыңлаучы, 3 нче зат- сөйләмдә катнашмый, аның турында сүз бара).119 нчы биттәге кагыйдә белән танышабыз. Әйдәгез эле, балалар, Аксакал әйткән сүзләрне кабат укып карыйк эле. (Хор)

- Яхшы, мин сезгә ул урлаган исемнәрегезне табып кайтарттырырмын.
- Җөмләдә сөйләүче зат кайсысы? (мин)

- Тыңлаучы затны әйтегез. (сез)
- Ул турында нәрсә әйтә аласыз? (Ул сөйләмдә катнашмый, аның турында сүз бара)
- Сез алмашлыгына игътибар итегез. Нәрсә әйтә аласыз? (Килеш белән төрләнгән).
- Укучылар безнең Аксакаллы картыбыз явыз карчыкны эзли-эзли янә яңа сынауга очрады, аңа ярдәм итик.

  Безнең зат алмашлыклары килеш белән төрләнә, ягез, дөрес итеп төрләндерик. Картка кемнең булышасы килә?
- **Беренче рәт укучылары 1 нче зат мин, без алмашлыкларын , ике укучы такта алдында 2 нче зат син.сез алмашлыкларын, 2 нче рәт укучылары 3 нче зат ул, алар алмашлыкларын килеш белән төрләндерә.**

  5 слайд

  Баш килеш кем?

  Иялек килеш кемнең?

  Юнәлеш килеш кемгә?

  Төшем килеш кемне?

  Чыгыш килеш кемнән?

  Урын-вакыт кемдә?
- **Укучылар, Афарин, укучылар!!!!**

  Физкультәнәфес.

  - Ә хәзер мин сезне ял итәргә чакырам. Парлашып бер-берегезгә карап басыгыз, һәм минем арттан кабатлагыз.(һәм курсәтегез хәрәкәтләр белән)

  Менә мин нинди үстем,
  Син дә шактый үскәнсең,
  Менә минем күзләрем,
  Менә синең күзләрең,
  Менә минем сул кулым,
  Менә минем уң кулым,
  Уң кулларны бирешик
  Булырсың минем дустым.

  - Рәхмәт, укучылар. Дус булып яшәгез бер –берегез белән!

Ә без барыбызнын да дуслары булган дәреслекләргә игтибар итәбез.
273 нче күнегү. Кошлар теле.
-Ничек уйлыйсыз балалар кайсы кош болай дип әйтә ала?
-Нинди кошларга оя ясыйбыз?
Дөрес, безнең иң яраткан кошчыгыбыз – ул сыерчык. Ул үзенең матур сайравы белән сокландыра һәм зарарлы бөҗәкләр ашап зур файда китерә.
Ә кайсыгыз сезнең шушындый ояны күргәне бар? Бәлки арагызда шушындый ояны ясаучылар да бардыр. Оялар матурмы, балалар? Матур!
Укучылар, әйтегез әле 2020 ел Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров тарафыннан нинди ел дип игълан ителде?
-Башкортстанда 2020 ел "Торак пунктларның эстетикасы елы"
Эстетика- (бор. грек. *сүзе*— «тойгы, хисләнү» дигәннән) — нәфис әдәбиятта, иҗатта, табигатьтә һәм тормышта матурлык дигәнне аңлата.
Димәк,әгәр дә без кошларга матур оялар ясап куйсак,ямьле табигатебезгә матурлык өстәрбез,шуның белән эстетика елыннан читтә калмабыз, тирә- юнебезне матурларга өлешебезне кертербез. Безнең туган җиребез кош оясы кебек матур, җылы, җырлы булсын!
Русия Президенты Владимир Путин тарафыннан 2020 нче ел Русиядә "Хәтер һәм дан елы" игълан ителде. Ничек уйлыйсыз ни өчен?
-Бөек Ватан сугышы тәмамлануга, ягъни Бөек Җиңүгә 75 ел.
Илебез халкы тиңдәшсез батырлыклар курсәтеп, фашистик Германияне җинде. Ә якташыбыз, татар егете Гази Заһитов Рейхстаг өстенә Җиңү байрагы элде.

Без Бөек Ватан сугышы каһарманнары һәм хөрмәтле ветераннарыбыз белән горурланабыз. Мондый дәһшәтле сугыш башкача кабатланмасын, кук йөзе һәрчак аяз булсын дигән теләктә дәресебезне дәвам итәбез.

Укучылар, безнең Аксакал карт явыз карчык янына барып җиткән, карчык аңа тиз генә бирешмәгән, ул безгә тагын бер җәза биргән. Булышабызмы картка? Хәзер сезнең алда тест биремнәре, шуны үтибез һәм дәрес өчен билгеләр алабыз.

1.Зат алмашлыкларына туры килә торган билгеләмәне күрсәт

а) исемне алмаштырып килә

б) предметның билгесен белдерә

в) предметны белдерә

2. Марат, Ләйлә, Алсу җиләккә киттеләр. Бу җөмләдәге кеше исемнәрен нинди зат алмашлыгы белән алыштырып була?

а) сез;

б) без;

в) алар

3. Без, сез, алар. Әлеге алмашлыклар нинди санда?

а) берлек

б) күплек

4. Син бик яхшы уйлагансың.

Бу җөмләдәге зат алмашлыгы:

а) 2 затта, берлек санда;

б) 2 затта, күплек санда;

в) 1 затта, берлек санда.

5. Бездән алмашлыгы нинди килештә килгән***?***

а) иялек килеше

б) чыгыш килеше

в) баш килеш

Билгеләр кую.

Йомгаклау.Укучылар, сезнең белемнәрегез явыз карчыкны җиңде. Аксакал калдырган алмашлыклар авыл халкына гына тугел, безгә дә ярдәм итте. Без алар турында бик куп мәглумат тупладык. Ә тырыш авыл кешеләре үзләренең исемнәрен сезнең ярдәм белән кире кайтардылар. Булдырдыгыз балалар!

Рефлексия

-Без сезнең белән бүген дәрестә нәрсә эшләдек? (зат алмашлыклары турында белемнәребезне тирәнәйттек.

-Зат алмашлыклары нәрсәләр белән төрләнә? (зат, сан, килеш)

Өйгә эш бирү.

1) 275 нче күнегү 120 биттә.
2) Зат алмашлыклары булган мәкальләр яз.
3) Әдәбият дәреслегеннән зат алмашлыклары кергән 5 җөмлә язып алырга,килешләрен билгеләргә.